## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17 ноябрь 2023 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керуче Түбән Чыршылы авылында 2024 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Түбән Чыршылы торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү (зират өчен хуҗалык бинасы урнаштыру, төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Түбән Чыршылы торак пуктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (махсус техникага хезмәт күрсәтү МТЗ - 82.1 тракторы, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (Түбәнге Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту, вак таш, ком алу);

4) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (Түбән Чыршылы торак пунктында янгын сүндерү сулыклары төзү, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов